**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Усады, ул. Советская, 41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет ур., 41

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**8 февраля 2021 г.** **№ 2**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге торак пунктларын киңәйткәндә төзелгән урамнарга исемнәр бирү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-28 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Хохлово авылы торак пунктының яңа урамнарына исем бирүне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегенең яңа урамнары атамалары реестры нигезендә бирергә: Нагорная урамы, Панорамная урамы, Офицерлар урамы, Төньяк Юл урамы.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Хохлово ав. торак пунктның яңа урамнары исеме реестрын расларга (1 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Ф.А.Зәбиров

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Усад авыл җирлеге Хохлово ав. торак пунктының
яңа урамнары атамалары
РЕЕСТРЫ**

| Урнашкан урыны | Урамнарның рус телендә атамасы | Урамнарның татар телендә атамасы |
|---|---|---|
| Хохлово авылы | улица Нагорная | Нагорная урамы |
| Хохлово авылы | улица Панорамная | Панорамная урамы |
| Хохлово авылы | улица Офицерская | Офицерлар урамы |
| Хохлово авылы | улица Проезд Северный | Төньяк Юл урамы |